**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЧЕРЕМШАНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**Улица М.Титова, дом 7,**
**Черемшан село, 423100**

**М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән**
**авылы, 423100**

**тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru**


**№ 58** **13 май 2022 ел**

# КАРАР

**Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль район вәкаләтләрен кабул итү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Муниципаль районның авыл җирлекләренә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында» 2022 елның 31 мартындагы 103 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен төзү, үзгәрешләр кертү өлешендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдимен кабул итү турында карар кабул итәргә.
2. Чирмешән авыл җирлеге башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына муниципаль район башлыгы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән авыл җирлеге

башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин